СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров, урамы 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 62 от 30.06.2021

на № ______ от _______________

# КАРАР

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр тапшыру, һәм керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

“Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елның 30 июненә кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы, Татарстан Республикасы Сабамуниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар, муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән гражданнар, һәм бу гражданнар бу вазыйфаларга билгеләнгән очракта үзенең керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар, үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырырга тиеш, бу Татарстан

Республикасы Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында»гы 2014нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 272 нче номерлы карары белән расланган, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар, шулай ук муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче гражданнар, Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла торган белешмәләр белән бергә, Россия Федерациясе Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указына 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча, үзенең, хатынының (иренең)  һәм балигъ булмаган балаларына цифрлы финанс активлары, бер үк вакытта цифрлы финанс активларын һәм башка цифрлы хокукларны, утилитар цифрлы хокукларны һәм цифрлы валютаны үз эченә алган цифрлы хокуклар турында хәбәрнамәләр тапшыралар, дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәтләр һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәтләр һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында»гы 2014нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 272 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәтләр һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәтләр һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы Нигезләмәгә 6 пунктның в) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре) цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча

һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр »;

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2017 елның 29 августында кабул ителгән 161 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре,чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә 3 пунктның г) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләрен), цифрлы финанс активларын, цифрлы валютаны сатып алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда муниципаль вазыйфаны биләүченең һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр».

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының «Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»2012 елның 7 сентябрендәге 139 номерлы карары белән расланган, Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә 2 пунктның г) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә һәм алыш-биреш башкарылган

акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр».

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов